ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 486 от «15» 12 2025 г.

2023-2025 елларга Татарстан
Республикасы Мамадыш муниципаль
районында Физик культура һәм
спортны үстерү» муниципаль программасына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү стратегиясе», «2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен, физик культураны һәм спортны үстерү стратегиясе» дәүләт программасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 2549-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 21 декабрендәге «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында Физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 435 номерлы каррарына ( алга таба –Карар) түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарның «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында Физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасының паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә. (1 нче кушымта).

1.2. 2023-2025 елларга Мамадыш муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү чараларында:

- 5 нче бүлектә: «Матди-техник базаны үстерү», 5.6 нчы пунктчага төзәтмәләр кертергә (2 нче кушымта);

2. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru/ рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М.Ефимовка йөкләргә.

Җитәкче А.М.Ефимов

0000013062

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
15 12 2025 ел,
№486 санлы карарына
1 нче кушымта

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | - Программаны финанслау Мамадыш муниципаль районы бюджеты акчалары, бюджеттан тыш чыганаклар, республика бюджеты акчалары исәбеннән җирле бюджетка бүлеп бирелгән күләмнәрдә һәм билгеләнгән тәртиптә бүлеп гамәлгә ашырылачак:<br>2023 ел - 93 695,5 мең сум<br>2024 ел - 106 492 мең сум<br>2025 ел - 108 244 мең сум<br>республика бюджеты:<br>2023 ел - 259,76 мең сум (спортинвентарь)<br>2024 ел - 202,99 мең сум (спортинвентарь)<br>2025 ел - 200,29 мең сум (спортинвентарь)<br>2025 ел – 167,4 мең сум (спортинвентарь өстәмә финанслау)<br>2023 ел – 456 мең сум (хоккей буенча программаларны гамәлгә ашыруга)<br>2024 ел – 657 мең сум (хоккей буенча программаларны гамәлгә ашыруга)<br>2025 ел – 679,9 мең сум (хоккей буенча программаларны гамәлгә ашыруга)<br>2023 ел - 3 899,7 мең сум (увеличение финансирования МБУ «СШ» Олимп»ны финанслауныарттыру (ябык футбол манежы») финанслауны арттыру). |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
15 12 2025 ел,
№486 санлы карарына
2 нче кушымта

# 5. Матди-техник базаны үстерү

| № | Чаралар исемлеге | Үтәлү вакыты | Үтәлү буенча җаваплы | Финанслау күләме (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 5.6 | Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алуга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә бюджетара трансфертлар (республика бюджеты). | 2023-2025 еллар | Мамадыш муниципаль районының “Хоккей һәм тимераякта фигуралы шуу буенча спорт мәктәбе” өстәмә белем бирү муниципаль учреждениесе, «СШ «Олимп»» өстәмә белем бирү МБУ | 259,76 | 202,99 | 367,69 |